КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 5 апрель г.Казань № 232

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 27 июнь, 608 нче; 2022 ел, 21 октябрь, 1130 нчы; 2022 ел, 11 ноябрь, 1204 нче; 2023 ел, 20 март, 279 нчы; 2023 ел, 29 май, 649 нчы, 2023 ел, 5 декабрь, 1561 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар

җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан өстәмә финанслана торган субсидия бирү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 5 апрель, 232 нче
карары редакциясендә)

## Бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан өстәмә финанслана торган субсидия бирү тәртибе

### I. Субсидия бирүнең гомуми нигезләмәләре һәм шартлары

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы бюджетыннан бөртекле культуралар җитештерүчеләргә (алга таба - сайлап алуда катнашучылар) агымдагы финанс елында һәм (яисә) хисап финанс елында үзе җитештергән бөртекле культуралар җитештерүгә һәм сатуга бәйле чыгымнарның (өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча) өлешен каплауга федераль бюджеттан финанслаша торган ( субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (алга таба - субсидия) билгели.

Субсидия агымдагы финанс елында һәм (яисә) хисап финанс елында субсидия алучылар тарафыннан тотылган бөртекле культураларны җитештерүгә һәм сатуга чыгымнарның бер өлешен каплауга үзе җитештергән сатылган бөртекле культураларның 1 тоннасына ставка буенча бирелә.

Өстәлгән бәягә салым исәпләүгә һәм түләүгә бәйле салым түләүченең вазыйфаларын үтәүдән азат итү хокукын файдаланучы субсидия алучылар өчен бөртекле культураларны җитештерүгә һәм сатуга чыгымнар өлешен каплау, өстәлгән бәягә салым суммасын да кертеп, товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алуга чыгымнар суммасыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

2. Бу Тәртиптә кулланыла торган төшенчәләр түбәндәгеләрне аңлата:

бөртекле культуралар – бодай, арыш, кукуруз, арпа. Күрсәтелгән культуралар бодай өчен ГОСТ 9353-2016 һәм ГОСТ 54078-2010, арыш өчен - ГОСТ 16990-2017 һәм ГОСТ 54079-2010, терлек азыгына арпа өчен - ГОСТ 28672-2019 һәм ГОСТ Р 53900-2010, кукуруз өчен - ГОСТ 13634-90 һәм ГОСТ Р 53903-2010 туры килергә тиеш;

сайлап алуда катнашучылар – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ашлык һәм ашлык эшкәртү продуктлары эзлекле рәвештә күзәтеп барыла торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2021 елның 9 октябрендәге 1722 номерлы карары белән расланган Ашлык һәм ашлык эшкәртү продуктлары эзлекле рәвештә күзәтеп барыла торган федераль дәүләт мәгълүмат системасын булдыру, аны үстерү һәм эксплуатацияләү кагыйдәләре (Ашлык һәм ашлык эшкәртү продуктлары эзлекле рәвештә күзәтеп барыла торган федераль дәүләт мәгълүмат системасында белешмәне һәм мәгълүматны теркәү һәм бирү кагыйдәләрен, белешмә һәм мәгълүмат бирү

формаларын һәм форматларын, мондый системадагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүгә карата таләпләрне, шулай ук мәгълүмат бирү турында грәсми сораулар җибәрү, шул исәптән гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән («Интернет» челтәрен һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү бердәм порталын да кертеп) файдаланып җибәрү формаларын һәм тәртибен кертеп) нигезендә Ашлык һәм ашлык эшкәртү продуктлары эзлекле рәвештә күзәтеп барыла торган федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Ашлыкны эзлекле рәвештә күзәтеп бару федераль системасы) теркәлгән авыл хуҗалыгы товары җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан тыш), шулай ук фәнни, фәнни-техник һәм (яки) белем бирү эшчәнлеге барышында авыл хуҗалыгы продукциясен (бөртекле культураларны) җитештерүне, аны беренчел һәм аннан соң (сәнәгый) эшкәртүне гамәлгә ашыра торган фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү мәгариф оешмалары.http://consultant.mship.local:8080/?req=doc&base=LAW&n=397906&dst=100018&field=134&date=30.01.2024

1. Субсидия Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 08 апрель, 235 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Агросәнәгать комплексын тармакларны үстерү һәм техник модернизацияләү» төбәк проекты кысаларында бирелә.

4. Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә бюджет акчаларын алучы буларак тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелде бюджет акчаларын баш бүлүче функцияләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органы - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба - Министрлык).

5. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба тиешенчә – бердәм портал, «Интернет» челтәре) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

6. Субсидияләр алучыларны сайлап алу (алга таба - сайлап алу) үткәрү ысулы - тәкъдимнәр (заявкалар) соратып алу (алга таба - заявка) - сайлап алу критерийларына һәм заявкалар керү чиратына туры килүдән чыгып, сайлап алу уздыру.

7. Субсидия алучы түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

бөртекле культуралар җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

Ашлык күзәтү федераль системасында үзләре җитештергән ашлык күләме турында мәгълүматлар булу.

8. Сайлап алу «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең

дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) гамәлгә ашырыла.

9. Министрлыкның сайлап алуда катнашучылар белән үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» системасында электрон рәвештә документлардан файдаланып гамәлгә ашырыла.

10. Сайлап алуда катнашучыларның «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

11. 2025 елның 1 гыйнварыннан акчалар бөртекле культуралар җитештерә торган җир кишәрлекләреннән файдалану хокуклары булу-булмауны документаль раслаган очракта җитештерү чыгымнары өлешен каплау һәм гамәлгә ашыру максатларында субсидия бирелә торган субсидия алучыларга бирелә.

12. Субсидия бирү ысулы - чыгымнарны каплау.

13. Каплау максаты белән субсидияләнә торган чыгымнарның юнәлешләре – үз җитештерүендәге бөртекле культуралар җитештерүгә бәйле чыгымнар (чәчүлек өчен кулланылган бөртекле культуралар орлыгы, ашламалар, бактерияле һәм башка препаратлар, үсемлекләрне зыян салынудан саклау чаралары, барлык төрләрдәге сатып алу энергиясе, технологик максатларда кулланыла торган барлык төрләрдәге нефть продуктлары, төп чараларны ремонтлау өчен запас частьләр һәм материаллар, инвентарь, приборлар, кораллар һәм башка хезмәт чаралары, хезмәт өчен түләү, социаль кирәк-яраклар өчен акча тотып калу, төп чараларны амортизацияләү, башка төркемнәргә кертелмәгән чыгымнар).

14. Субсидия алучыга бирелергә тиешле субсидия күләме (Wф)(сумда) исәпләп чыгару түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$W_{ф} = \sum_{i=1}^{n}\left(V_{фi} \times C \times K_{страх}\right) \leq \sum_{i=1}^{n}\left(V_{фi} \times S_{i} \times 50\%\right),$$

монда:

i – бөртекле культураларның төре;

n – бөртекле культураларның саны;

Vфi - сайлап алу үткәрелү турында игълан ителгән чорда үз производствосының i-бөртекле культурасын сайлап алуда катнашучы тарафыннан гамәлгә ашырылган факттагы күләм;

С – реализацияләнгән 1 тонна үз җитештерүендәге бөртекле культураларга субсидия ставкасы, аның күләме Министрлык боерыгы белән раслана һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = \frac{W_{б}}{R_{рф}},$$

монда:

Wб - Министрлыкка әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре күләме, мең сум;

$R_{рф}$ – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында субсидия алучыларга бөртекле культуралар җитештерү һәм аларны реализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасына субсидияләр бирү турында төзелә торган килеәү нигезендә Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы буенча үз җитештерүендәге бөртекле культураларны реализацияләү күләме мең тонна;

$K_{страх}$ – субсидия ставкасына кулланыла торган 0,5 тигез коэффициенты, җитештерү һәм сату чыгымнарының бер өлешен каплау максатларында субсидия бирелә торган билгеле бер бөртекле культура җитештергәндә мондый бөртекле культураның уңышын югалту (юкка чыгу) рискына бәйле мөлкәт характерындагы мәнфәгатьләргә дәүләт ярдәме күрсәтеп, авыл хуҗалыгы иминләштерелмәгән булса;»;

$S_i$ – хисап финанс елында җитештерелгән бөртекле культураларның үзкыйммәте (тонналы сумнарда), хисап финанс елында үсемлекчелек продукциясен җитештерү, аның чыгымнары, үзкыйммәте һәм аны реализацияләү турында бухгалтерлык хисаплылыгы мәгълүматы нигезендә хисап финанс елында җитештерелгән i бөртекле культураның үзкыйммәте (1 тоннага сумда).

Әгәр субсидия алучылар тарафыннан реализацияләнгән бөртекле культураларның фактагы күләме Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән Татарстан Республикасы буенча үз җитештерүендәге бөртекле культураларны реализацияләү күләменнән (мең тоннада) артып киткән булса, субсидия алучыга бирелергә тиешле субсидия суммасы (W) Министрлык тарафыннан түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = \sum_{i=1}^{n}\left(V_{фi} \times K \times K_{страх}\right) \times C \leq \sum_{i=1}^{n}\left(V_{фi} \times S_i \times 50\%\right),$$

монда:

К – субсидия алучылар тарафыннан реализацияләнгән, каплауга тәкъдим ителгән, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган бөртекле культуралар күләмен корректировкалау коэффициенты:

$$K = \frac{R_{рф}}{\sum_{j=1}^{k}\left(\sum_{j=1}^{n} V_{фi} \times K_{страх}\right)},$$

монда:

j – субсидия алучы;
k – субсидия алучылар саны.
15. Субсидия бирү нәтиҗәсе - ашлык җитештергән бөртекле культураларның сайлап алуны уздыру турында игълан ителгән чорда сатылган күләме (мең тонна).

## II. Сайлап алуда катнашучыларга таләпләр

16. Заявканы карау һәм субсидия бирү турында килешү төзү даталарына (алга таба - килешү) сайлап алуда катнашучы түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты түгел;

сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

сайлап алуда катнашучының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән

бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычы булмау;

юридик зат булган сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау, ә индивидуаль эшмәкәр булган сайлап алуда катнашучы үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмау.

17. Сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 16 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү автомат рәвештә «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба - дәүләт мәгълүмат системасы) белешмәләре нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең ярдәм системасын кулланып, гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Министрлыкның файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта Министрлык сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 16 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел, сайлап алуда катнашучы күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән Министрлыкка тапшырырга әзер булган очрактан тыш.

«Электрон бюджет» системасында автомат тикшерүне гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 16 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау сайлауда катнашучы тарафыннан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәү турында тамгаларны электрон рәвештә язып кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

## III. Сайлап алуны уздыру турында игълан булдыру һәм урнаштыру тәртибе

18. Сайлап алуны уздыру турында игълан Министрлык тарафыннан Министрлык “Электрон бюджет” системасында игъланны формалаштырылган көннән алып бер календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән зат) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза салынганнан һәм субсидия турындагы мәгълүматның бердәм порталында бастырып чыгарылганнан соң урнаштырыла.

19. Сайлап алуны уздыру турында игълан Министрлыкның «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаша, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән зат) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда бастырыла, түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасын, шул ук вакытта заявкаларны кабул итеп алу тәмамлану датасы сайлап алу үткәрү турында белдерү

урнаштырылган көннең иртәгесеннән 10 календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 15 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсе;

«Интернет» челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яисә) битләре күрсәткечләре;

сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртип белән билгеләнгән даталарга туры килергә тиешле әлеге Тәртипнең 16 пункты белән билгеләнгән сайлап алуда катнашучыларга һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен конкурста катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

сайлап алу критерийлары;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкалар бирү тәртибе һәм әлеге Тәртипнең 25 – 30 пунктлары нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

бу Тәртипнең 31 пункты нигезендә заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 34 – 37 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

заявкаларны эшләп бетерү өчен кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кире кагу тәртибе, шулай ук әлеге Тәртипнең 38 пункты нигезендә аларны кире кагу нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алуның җиңүчесенә (җиңүчеләргә) бирелә торган субсидиянең максималь, минималь күләмен үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидияне бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

конкурста катнашучыларга әлеге Тәртипнең 32 - 33 пунктлары нигезендә сайлап алуны уздыру турында игълан итүнең аңлатмаларын бирү тәртибе, мондый бирүне башлау датасы һәм төгәлләү вакыты;

сайлап алуның җиңүчесе (җиңүчеләре) әлеге Тәртипнең 47 пункты нигезендә килешү имзаларга тиеш вакыт;

сайлап алуның җиңүчесен (җиңүчеләрен) әлеге Тәртипнең 53 пункты нигезендә килешү төзүдән читләшкән дип тану шартлары;

бердәм порталда, шулай ук «Интернет» челтәрендә https://agro.tatarstan.ru Министрлыкның рәсми сайтында (алга таба - Министрлыкның рәсми сайты) сайлап алу йомгакларын үткәрү беркетмәсен урнаштыру сроклары, сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннән соң килүче 14 нче календарь көннән соң була алмый.

## IV. Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару тәртибе

20. Бердәм порталда сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында Министрлык тарафыннан игълан урнаштыру конкурста катнашучыларның заявкаларын бирү срогы тәмамланганчы бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

21. Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында игълан электрон рәвештә

“Электрон бюджет” системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән төзелә, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла һәм сайлап алуны гамәлдән чыгару сәбәпләре турында мәгълүмат туплана.

Сайлап алуны гамәлдән чыгару очрагы булып әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары кире алу тора.

22. Заявкалар биргән сайлап алуда катнашучылар «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны үткәрүне юкка чыгару турында мәгълүмат бирәләр.

23. Сайлап алу аны гамәлдән чыгару турындагы игълан бердәм порталда урнаштырылган көннән сайлап алу гамәлдән чыгарылган дип санала.

24. Әлеге Тәртипнең 20 пункты нигезендә сайлап алуны юкка чыгару срогы тәмамланганнан соң һәм субсидия бирү турында карар кабул ителгәнчегә кадәр Министрлык Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә җиңеп булмый торган көч шартлары барлыкка килгән очракта гына сайлап алуны юкка чыгарырга мөмкин.http://consultant.mship.local:8080/?req=doc&base=LAW&n=452991&dst=101922&field=134&date=27.01.2024

## V. Заявкаларны формалаштыру һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирү тәртибе

25. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән срокларда заявканы «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә төзи һәм бирә һәм «Электрон бюджет» системасына документларның электрон күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) тапшыра:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ашлык һәм ашлык эшкәртү продуктларын күзәтеп барыла торган федераль дәүләт мәгълүмат системасында ашлык партиясенә яки ашлык эшкәртү продуктлары продуктлары партиясенә товарның ияրчен документын рәсмиләштерү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 9 октябрендәге 1721 номерлы карары белән расланган Ашлык һәм ашлык эшкәртү продуктларын күзәтеп барыла торган федераль дәүләт мәгълүмат системасында ашлык партиясенә яки ашлык эшкәртү продуктлары продуктлары партиясенә товарның иярчен документын рәсмиләштерү кагыйдәләре (алга таба – Товарның иярчен документын рәсмиләштерү кагыйдәләре) нигезендә рәсмиләштерелгән ашлык партиясенә яки ашлык эшкәртү продуктлары продуктлары партиясенә товарның иярчен документлары белән раслана торган үз җитештерүендәге бөртекле культуралар җитештерү күләмнәре турында белешмә;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча хисап финанс елына үсемлекчелек продукциясен җитештерү, аның чыгымнары, үзкыйммәты һәм аны реализацияләү турында бухгалтерлык хисаплылыгы мәгълүматы нигезендә бөртекле

культуралар җитештерүнең факттагы үзкыйммәте (чәчүлек өчен кулланылган бөртекле культуралар орлыгы, ашламалар, бактерияле һәм башка препаратлар, үсемлекләрне зыян салынудан саклау чаралары, барлык төрләрдәге сатып алу энергиясе, технологик максатларда кулланыла торган барлык төрләрдәге нефть продуктлары, төп чараларны ремонтлау өчен запас частьләр һәм материаллар, инвентарь, приборлар, кораллар һәм башка хезмәт чаралары, хезмәт өчен түләү, социаль кирәк-яраклар өчен акча тотып калу, төп чараларны амортизацияләү, башка төркемнәргә кертелмәгән чыгымнар) турында белешмә кәгазе;

товарның иярчен документын рәсмиләштерү кагыйдәләре нигезендә рәсмиләштерелгән ашлык партиясенә яки ашлык эшкәртү продуктлары партиясенә товарның иярчен документлары белән раслана торган, сайлап алу үткәрү турында игъланда үз җитештерүендәге бөртекле культураларны реализацияләү фактын раслый торган документлар (шартнамәләр, товар-транспорт накладнойлары һәм (яки) универсаль тапшыру документлары, реализацияләнгән продукцияләүгә түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре);

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча субсидия күләмен исәпләү;

субсидия бирелә торган җитештерү һәм реализацияләү чыгымнарының бер өлешен кире кайтару максатларында бөртекле культуралар чәчүлекләре биләгән җир кишәрлекләренә карата төзелгән дәүләт ярдәме белән авыл хуҗалыгын иминләштерү шартнамәләре;

салым түләүченең өстәлгән кыйммәткә салым исәпләүгә һәм түләүгә бәйле йөкләмәләрен үтәүдән азат итү хокукыннан файдаланучы сайлап алуда катнашучыларның өчен салым салуның кулланыла торган системасы турында салым органыннан белешмә кәгазе;

2025 елның 1 гыйнварыннан - бөртекле культуралар җитештерү гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләреннән файдалану хокуклары булуны раслый торган документлар, аларны җитештерү һәм гамәлгә ашыру чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидия бирелә.

26. Заявка сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

27. Заявкада булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә сайлап алуда катнашучы җаваплы була.

28. Заявкага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре барлык документны йә аның өлешен карау мәгълүматны карауны һәркем файдалана алырлык программа белән тәэмин итү чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга тиеш һәм махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яисә якланган булырга тиеш түгел.

Заявкага кертелгән фото- һәм видеоматериалларда югары сыйфатлы ачык һәм контрастлы сурәт булырга тиеш.

29. Сайлап алуда катнашучының заявка бирү датасы булып заявкага “Электрон

бюджет” системасында теркәлү номеры бирелеп, аңа сайлап алуда катнашучы тарафыннан имза салынган көн санала.

30. Заявкада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) сайлап алуда катнашучы турында мәгълүмат һәм документлар:

сайлап алуда катнашучының тулы һәм кыскартылган исеме (юридик затлар өчен);

индивидуаль эшкуарл фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

сайлап алуда катнашучының төп дәүләт теркәве номеры (юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар өчен);

салым түләүченең идентификация номеры;

салым органында исәпкә кую датасы (индивидуаль эшкуарлар өчен);

салым органында исәпкә куелу датасы һәм коды (юридик затлар өчен);

физик затны индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәве датасы;

юридик зат адресы, теркәлү адресы (индивидуаль эшкуарлар өчен);

элемтә телефоны номеры, почта адресы һәм юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен электрон почта адресы;

юридик зат җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), салым түләүченең идентификация номеры, вазыйфасы);

сайлап алуда катнашучы оешманың гамәлгә кую документлары нигезендә (юридик затлар өчен) яисә индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестры белешмәләре нигезендә (индивидуаль эшкуарлар өчен) гамәлгә ашырырга хокуклы төп һәм өстәмә эшчәнлек төрләре исемлеге;

субсидияне күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук килешүне имзалауга вәкаләтле зат турында мәгълүмат;

б) сайлап алуда катнашучының сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән таләпләргә һәм критерийларга туры килүен раслый торган мәгълүмат һәм документлар;

в) «Интернет» челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән заявка турында, шулай ук «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән бирелә торган субсидияне сайлап алуга һәм аның нәтиҗәсенә бәйле рәвештә сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын раслау;

г) сайлап алуда катнашучы тәкъдим итә торган субсидия бирү нәтиҗәсе, соратып алына торган субсидия күләме.

31. Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда сайлап алуда катнашучы заявкалар бирү өчен билгеләнгән вакыт эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

Заявкага үзгәрешләр кертү яисә заявканы кире алу әлеге Тәртипнең 25 пунктында күрсәтелгән сайлап алуда катнашучының заявкасын төзүнең шундый ук тәртибендә сайлап алуда катнашучы тарафыннан гамәлгә ашырыла.http://consultant.mship.local:8080/?req=doc&base=LAW&n=463135&dst=100152&field=134&date=28.01.2024

32. Бердәм порталда сайлау үткәрү турында игълан урнаштырылган көннән

башлап, сайлауның теләсә кайсы катнашучысы, сайлау тәмамланган көнгә кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча «Электрон бюджет» системасында тиешле гарызнамә төзү юлы белән сайлап алуны үткәрү турында игълан итү нигезләмәләрен аңлату турында Министрлыкка иң күбе биш гарызнамә җибәрергә хокуклы.

33. Министрлык әлеге Тәртипнең 32 пунктында күрсәтелгән гарызнамәгә җавап итеп күрсәтелгән игълан белән билгеләнгән срокта, әмма заявкалар бирү тәмамланган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле аңлатманы «Электрон бюджет» системасында булдыру юлы белән сайлап алуны уздыру турындагы игълан нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Министрлык тарафыннан сайлап алуны уздыру турында игълан итү нигезләмәләрен аңлату күрсәтелгән белдерүдә булган мәгълүматның асылын үзгәртергә тиеш түгел.

«Электрон бюджет» системасында формалаша торган аңлатмадан файдалану әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә сайлап алуның барлык катнашучыларына бирелә.

VI. Заявкаларны карау тәртибе, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү

34. Заявкаларны карау Министлыкның Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районнарында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре (алга таба - Идарә) тарафыннан “Электрон бюджет” системасында заявкаларны карау Министрлык һәм Идарәләргә керү мөмкинлеге ачылган көннән соң килүче 15 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Министрлыкка һәм Идарәләргә «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге сайлап алуны үткәрү турында игъланда билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча ачыла.

«Электрон бюджет» системасында Министрлык тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланганчы бер дата билгеләнергә мөмкин, шуннан соң Министрлыкка һәм Идарәләргә «Электрон бюджет» системасында сайлауда катнашучыларга бирелгән заявкаларга керү ачыла.

35. Министрлык сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән заявкаларны ачу көненнән соң килгән бер эш көненнән дә соңга калмыйча заявкаларны ачу беркетмәсен имзалый, алар сайлауда катнашу өчен килгән заявкалар турында түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

а) заявканы теркәү номеры;

б) заявка керү датасы һәм вакыты;

в) сайлап алуда катнашучының тулы исеме (юридик затлар өчен) яисә фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (индивидуаль эшкуарлар өчен);

г) юридик зат адресы, теркәлү адресы (индивидуаль эшкуарлар өчен);

д) сайлап алуда катнашучы тарафыннан соратып алына торган субсидия күләме.

36. Заявкаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

37. Әгәр ул сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә

туры килсә һәм заявканы кире кагу өчен нигезләр булмаганда, заявка дөрес дип танылa.

Заявканың сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турындагы карарлар заявка составында тапшырылган мәгълүматны һәм документларны сайлап алу нәтиҗәләрен тикшерү көненә Идарә тарафыннан кабул ителә.

38. Заявканы карау стадиясендә заявканы кире кагу өчен нигезләр түбәндәгеләр тора:

а) сайлауда катнашучының сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

б) сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

в) тапшырылган документларның һәм (яисә) заявкаларның сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

г) заявка составында тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

д) сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе.

39. Заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча, заявкаларны карау срогы тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан заявкаларны карау беркетмәсе әзерләнә, ул кергән һәм каралган заявкаларның саны турында мәгълүматны, шулай ук сайлап алуның һәр катнашучысы буенча аның заявкасын тиешле дип тану яисә, кире кагу өчен нигезләр күрсәтелеп, аның заявасын кире кагу турында мәгълүматны үз эченә ала.

40. Заявкаларны карау беркетмәсе заявкаларны карау нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

41. Сайлау түбәндәге очракларда булмаган дип танылa:

а) заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

б) заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кире кагылган.

42. Кергән заявкаларны тәртипкә салу аларның керү чиратыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

43. Сайлап алуда җиңүчеләр дип Министрлык тарафыннан сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән бүлеп бирелә торган субсидия күләме чикләрендә кергән заявкаларны ранжировкалау нәтиҗәләре буенча төзелгән рейтингка кертелгән сайлап алуда катнашучылар танылa.

44. Сайлап алуны төгәлләү һәм җиңүчеләрне ачыклау максатларында сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсе төзелә. Сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсе сайлап алу җиңүчеләрен билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм “Электрон бюджет” системасында Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук бердәм порталда аңа кул куйган көннең икенче эш көненнән дә

соңга калмыйча урнаштырыла, һәм сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла. Беркетмәгә түбәндәге белешмәләр керә:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

45. Әлеге Тәртипнең 44 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыга бирү өчен каралган субсидия күләмен сайлап алу йомгаклары беркетмәсендә күрсәткәндә ул сораган субсидия күләме әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибенә туры килмәгән очракта Министрлык мондый сайлауда катнашучы өчен каралган субсидия күләмен төзәтергә мөмкин, әмма ул заявкада күрсәтелгән күләмнән югарырак булмаска тиеш.

46. Сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия әлеге Тәртипнең 43 пунктында күрсәтелгән рейтингка кертелгән сайлап алуда катнашучылар арасында түбәндәге ысул белән бүленә: рейтингта беренче тәртип номеры бирелгән сайлап алуда катнашучыга заявкада күрсәтелгән күләмнең мәгънәсенә тигез субсидия күләме бүленә, әмма әлеге Тәртипнең 14 пункты нигезендә исәпләнгән субсидия күләменнән югары түгел.http://consultant.mship.local:8080/?req=doc&base=LAW&n=463135&dst=100259&field=134&date=02.02.2024

Сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия беренче тәртип номеры бирелгән сайлап алуда катнашучының заявкасында күрсәтелгән субсидияләр күләме күбрәк булса, субсидиянең калган күләме рейтингка кертелгән сайлап алуда калган катнашучылар арасында бүленә.

Рейтингка кертелгән һәр сайлап алуда катнашучыга заявкада күрсәтелгән күләмгә тигез субсидия күләме бүленә, әмма әлеге Тәртипнең 14 пункты нигезендә исәпләнгән субсидия күләменнән югары түгел, күрсәтелгән күләм субсидиянең бүленмәгән күләменнән кечерәк йә аңа тигез булса.

Заявкада сайлап алуда катнашучы күрсәткән субсидия күләме бүленмәгән субсидия күләменнән зуррак булган очракта, сайлап алуда катнашучының ризалыгы белән сайлап алуның мондый катнашучысына калган субсидиянең барлык күләме бүленә, әмма әлеге Тәртипнең 14 пункты нигезендә исәпләнгән субсидия күләменнән югары түгел, сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявкада күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсен үзгәртмичә.

## VII. Килешүләр төзү һәм субсидия күчерү тәртибе

47. Министрлык сайлап алу нәтиҗәләре буенча сайлап алуның җиңүчесе (җиңүчеләре) белән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә сайлауның җиңүчесе (җиңүчеләре) билгеләнгәннән соң 20 эш

көненнән дә соңга калмыйча килешү төзи.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ рәвешендә төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куела.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Министрлыкка элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта килешүгә килешүнең яңа шартларын килештергәндә яисә яңа шартлар буенча килештерелмәгәндә килешүне өзү турында шарт кертелә.

Министрлык, кирәк булганда, субсидия алучы белән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

48. Юридик зат булган субсидияне алучыны кушылу, кушу яисә үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп төзегәндә, килешүгә, хокук варисы булган юридик затны килешүдә күрсәтеп, мәҗбүри рәвештә затны алмаштыру өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәрешләр кертелә.

Юридик зат булган субсидияне алучыны бүленү, бүлеп бирү рәвешендә үзгәртеп төзегәндә, шулай ук юридик зат булган субсидия алучы юкка чыгарылганда, яки индивидуаль эшкуар булган субсидия алучының эшчәнлеге туктатылганда (Россия Федерациясе Граждан кодексының 23 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацы нигезендә крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы буларак эшчәнлек алып баручы индивидуаль эшкуардан тыш), килешү берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә һәм, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән йөкләмәләр турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне башкару һәм субсидиянең файдаланылмаган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кайтару турында акт төзеп фомалаштырыла.

Россия Федерациясе Граждан кодексының 23 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацы нигезендә крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы буларак эшчәнлекне гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуар булган, үз хокукларын башка гражданга «Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында» 2003 елның 11 июнендәге 74-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә тапшыра торган субсидия алучының эшчәнлеге туктатылганда килешүгә, хокук варисы булган башка зат килешүендә якларны күрсәтеп, затны үзгәртү өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәрешләр кертелә.

49. Министрлык сайлауда җиңүченең сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве факты ачыкланган очракта яисә сайлауда җиңүче тарафыннан дөрес булмаган мәгълүмат тәкъдим ителгән очракта сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тарта.

50. Министрлык әлеге Тәртипнең 49 пунктында каралган нигезләрдә сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тарткан очракта, сайлап алуда җиңүче килешү төзүдән баш тарткан очракта, сайлап алуны үткәрү турында игъланда билгеләнгән срокта сайлап алуда җиңүче килешүне имзаламаган очракта Министрлык сайлап алуның соратып алына торган күләме өлешендә заявкалары тулы күләмдә канәгатьләндерелмәгән сайлап алуда җиңүче дип танылган башка катнашучыларга субсидия күләмен һәм аны бирү нәтиҗәләрен арттыру турындагы

тәкъдим җибәрә яки заявкасы кимү тәртибендә киләсе заявка рейтингына ия дип танылган сайлап алуда җиңүче белән килешү төзи.

51. Сайлап алуны уздыру нәтиҗәләре буенча сайлап алу җиңүчеләре арасында бүленмәгән тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитларының калган өлеше булган, бюджет йөкләмәләре лимитларын арттырган, җиңүче килешүне төзүдән баш тарткан, субсидия алучы белән килешүне өзгән очракта, Министрлык әлеге Тәртип нигезләмәләре нигезендә өстәмә сайлап алуны уздыру турында карар кабул итәргә мөмкин.

52. Агымдагы финанс елы чикләрендә Министрлыкка субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары арттырылган, сайлап алу җиңүчесе килешү төзүдән баш тарткан, субсидия алучы белән килешү өзелгән һәм сайлап алуны узган һәм субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары җитәрлек булмау сәбәпле сайлап алуда җиңүче дип танылмаган яки заявкалары соратып алына торган күләм өлешендә тулы күләмдә канәгатьләндерелмәгән сайлап алуда җиңүчеләр дип танылган сайлап алуда катнашучылар булган очракларда субсидия рейтингта элек бирелгән номерны исәпкә алып кабат сайлап алуны үткәрмичә бүленергә мөмкин яисә Министрлык карары буенча сайлап алуда җиңүчеләргә субсидияләр күләмен һәм субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсен арттыру турындагы тәкъдим җибәрелергә мөмкин.

53. Сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә кул куюы тәэмин ителмәгән очракта, субсидия алучы килешү төзүдән читләшкән дип танила.

54. Министрлык килешүләр төзүне төгәлләү срогын сайлап алуны уздыру турында игълан ителгән көннән алып бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча субсидия алучыларга субсидияләр бирү турында карар кабул итә, ул Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнүе.

55. Министрлык субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча үз шәхси счетыннан Идарәләрнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетларына акча күчерә.

Идарәләр үз шәхси счетына акча кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә акчаны аларны алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына күчерә.

## VIII. Субсидияләр бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны контрольдә тотуны (мониторинглауны) гамәлгә ашыру хисабын бирү тәртибе

56. Субсидия алучы «Электрон бюджет» системасында килешүләр өчен Россия

Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма буенча килешү төзегән көннән алып өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе ирешү турында хисап тапшыра.

57. Министрлык, күрсәтелгән хисап тапшырылган көннән алып өч эш көненнән артмаган срокта, субсидия бирү нәтиҗәсенең әһәмияте турындагы хисапны тикшерә.

58. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

59. Субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган очракларда, субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылганда, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган очракларда, шулай ук субсидия бирү күрсәткече нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешелмәгән очракта, бирелгән субсидия Татарстан Республикасы бюджеты керемен тулы күләмдә, Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсен алган көннән алып календарь көннәрдә исәпләнгән 30 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

60. Бу Тәртипнең 59 пунктында күрсәтелгән акча Татарстан Республикасы бюджеты керемен ирекле рәвештә кире кайтарылудан баш тартылган очракта, алар Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә 30 көн эчендә түләтелергә тиеш.

_______________________